**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 23 апрель № 277

г. Казань

Казан шәһәре, Петербург урамы, 52 йорт адресы буенча урнашкан бина фасадына мемориаль такта кую турында

1941 – 1945 елларда Бөек Ватан сугышында катнашучылар – татарстанлылар хәтерен мәңгеләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Казан шәһәре, Петербург урамы, 52 йорт адресы буенча урнашкан бина фасадына мемориаль такта кую турында, рус һәм татар телләрендәге түбәндәге текст белән, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, “ИТ-парк” югары технологияләр тармагында технопарк” дәүләт автоном учреждениесе тәкъдимен кабул итәргә:

“В этом здании в 1941 – 1945 годах
располагался сборный пункт Военного комиссариата Татарской АССР.
В годы Великой Отечественной войны в республике были сформированы:
7 стрелковых дивизий,
1 авиационная дивизия,
1 танковая бригада,
86 авиаполков
и другие подразделения.
Из Татарстана ушли на фронт более 700 тысяч человек,
из них свыше 350 тысяч не вернулись с полей сражений.
Подвиг наших земляков останется в веках.
Вечная память героям!

___________

1941–1945 елларда бу бинада
Татарстан АССР Хәрби комиссариатының җыелу пункты урнашкан була.
Бөек Ватан сугышы елларында республикада
7 укчылар дивизиясе,
1 авиация дивизиясе,

1 танк бригадасы,
86 авиаполк
һәм башка подразделениеләр оештырыла.
Татарстаннан фронтка 700 меңнән артык кеше китә,
аларның 350 меңнән артыгы яу кырларыннан кайтмый.
Якташларыбыз батырлыгы беркайчан да онытылмас.
Геройларга мәңгелек дан!”.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\277.doc